ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЧУТЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧҮТИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 ел, 19 февраль** **Чүти авылы** **№ 2**

**Муниципаль районның җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге турындагы мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәре аша мәгълүмат белән тәэмин итү мөмкинлеге турында**

2006 елның 27 нче июлендә чыккан 149-ФЗ номерлы «Мәгълүмат, информацион технологияләр һәм мәгълүмат саклау турында» Федераль законы, 2009 елның 9 нчы февралендә чыккан 8-ФЗ номерлы «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законы, 2015нче елның 16нчы гыйнварында чыккан 3-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт органнары Һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында», Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә ачыклыкны Һәм муниципаль мәгълүмат ресурсларының һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү, җирле үзидарә органнары, гражданнар Һәм юридик затлар арасында нәтиҗәле эшчәнлеккә өчен шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1.Түбәндәге кушымталарны расларга:

1.1 Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлегенең рәсми сайты турында нигезләмә;
1.2 Муниципаль районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат- телекоммуникация «Интернет» челтәрендә урнаштырыла торган мәгълүмат исемлеге;
1.3 Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлегенең рәсми сайтында мәгълүмат бастырып чыгару тәртибе;
1.4 Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлегенең рәсми сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә файдалануны тәэмин итү технология, программа Һәм лингвистик чараларына карата таләпләр.

2.Әлеге карарны Интернет челтәренен мәгълүмат-телекоммуникация «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталын»да http://pravo.tatarstan.ru веб- адресы буенча, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге сайтында Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендэге http://chuteev-kaybici.tatarstan.ru веб- адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Чүти авыл җирлеге башлыгы** **Тараканов П. П.**